**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**МУСЛЮМОВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ КРЯШ-ШУРАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЕРЭШ-ШУРАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

423978, Р.Т. Муслюмовский район, с. Кряш-Шуран, улЦентральная 6а,
Kshur.Mus@tatar.ru тел. (8-85556) 3-35-45
ИНН 1629001057, КПП 162901001, ОГРН 1021605558732, ОКАТО 92242825000,
ОКТМО 92642425

**КАРАР**
09 гыйнварь 2019 ел

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
№ 1

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлегендә 2019 елда Үзара салым түләүне (үзара салым) бер тапкыр җыюны оештыру һәм үзара салым акчалары тотыла торган төзекләндерү чаралары исемлеге турында**

Татарстан Республикасының 2004 елның 24 мартындагы № 23-ТРЗ “Җирле референдум турындагы законы”, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 18 ноябрендәге № 367 “Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлегендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында” карарына нигезләнеп, 2019 елда Керэш-Шуран авыл җирлегендә бер тапкыр түләү (үзара салым) акчаларын үз вакытында җыю максатыннан карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Керэш-Шуран авыл җирлегендә 2019 елга, референдумда тавыш бирү хокукына ия, 18 яше тулган җирлектә яшәүче һәр кешедән 1000 сум күләмендә бер тапкыр түләү (үзара салым) күләмен расларга.

2. Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, I, II төркем инвалидлары, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, чернобыль катастрофаларында авыру алган яки кичергән гражданнарга, 500 (биш йөз) сум күләмендә түләүне билгеләргә.

3. Бер тапкыр түләү вакытын 2019 елнын 10 апреленә кадәр расларга.

4. Авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карар буенча үзара салым акчаларын җыюны оештырырга һәм авыл җирлеге Советы алдында хисап тотарга.

5. Үзара салым акчасы тотыла торган төзекләндерү буенча чаралар исемлеген расларга. (1нче кушымта)

6. Авыл җирлеге башкарма комитетына үзара салым акчаларын чын исемлектән тотарга һәм авыл җирлеге Советы алдында хисап тотарга.

7. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында Керэш-Шуран авыл җирлеге битендә түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://muslumovo.tatarstan.ru/rus/krshur.htm.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

**Авыл җирлеге башлыгы** **Р.Г.Сафиуллин**

Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлеге башлыгы 2019 елның 09 гыйнварендә кабул ителгән №1 карарына 1 кушымта

**Керәш-Шуран авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы тотыла торган төзекләндерү буенча чаралар исемлеге**

1. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

2. Халыкның ялын оештыру максатыннан шартлар тудыру;

3. Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

4. Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру;

5. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә төзекләндерү эшләрен оештыру;

6. Урам-юл челтәре, җирлек чикләрендә элементларга исем бирү;

7. Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнашу;

8. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

9. Җирлектә халыкны су белән тәэмин итү;

10. Җирлектәге урам юлларын карап тору;

11. Җирлек халкы күпләп ял итә алсын өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми кулланылыштагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итү .

12. Җирлекнең территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау;

13. Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннарны тоту һәм карап тоту буенча чараларны гамәлгә ашыру.

**Авыл җирлеге башлыгы:** **Р.Г.Сафиуллин**